КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 08 июнь г.Казань № 539

Казан шәһәре чикләрендә Казансу елгасы акваториясендә триатлон буенча Россия чемпионатын уздырганда су объектларыннан файдалану турында

Россия Федерациясе Су кодексының 6 һәм 25 статьялары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, 23 апрель, 256 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләренең 1.3 пункты нигезендә, Казан шәһәре чикләрендә Казансу елгасы акваториясендә триатлон буенча Россия чемпионатын уздырганда кешеләрнең тормыш куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларындаТатарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ :

1. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Казансу елгасында Кремль дамбасыннан алып "Миллениум" күперенә кадәр участокта аз үлчәмле, йөрүче, спорт-җилкәнле судноларны куллануны тыярга:

2022 елның 17 июнендә 09.00 дан 18.00 сәгатькә кадәр,

2022 елның 18 июнендә 05.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр;

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән суднолардан файдалануны тыю Казан шәһәре чикләрендә Казансу елгасы акваториясендә триатлон буенча Россия чемпионатын әзерләү һәм уздыру өчен файдаланыла торган судноларга кагылмый.

2. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына:

әлеге карар белән билгеләнгән тыюны үтәү максатларында күрсәтелгән участокларда көчләрнең һәм чараларның кизү торуын тәэмин итәргә;

халыкка кертелә торган тыю турында, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша мәгълүмат бирү эшен оештырырга.

3. Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенә әлеге карарда билгеләнгән тыюны үтәү максатларында көчләрнең һәм чараларның кизү торуны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин